**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан; сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчанхәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, срочный хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1. торак пункт территориясен төзекләндерү МТЗ-82.1 тракторы (карап тоту һәм хезмәт күрсәтү)(ягулык-майлау материаллары сатып алу, алгы шиннар сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, юлларны кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү һәм башка төр эшләр); Федотовка авылында Совет урамында балалар мәйданчыгы урнаштыру);

2. торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары, Таулы, Күл, Түбән, Яңа, Мурашев урамнарындагы вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу)

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 284 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 151 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 149 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 2 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан; сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчанхәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, срочный хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2025 елда 400 (Дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

торак пункт территориясен төзекләндерү МТЗ-82.1 тракторы (карап тоту һәм хезмәт күрсәтү)(ягулык-майлау материаллары сатып алу, алгы шиннар сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, юлларны кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү һәм башка төр эшләр); Федотовка авылында Совет урамында балалар мәйданчыгы урнаштыру);

2. торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары, Таулы, Күл, Түбән, Яңа, Мурашев урамнарындагы вак таш түшәлгән юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу)

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет ур., 6 й., Совет ур., 8 й. (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 й. (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Федотовка авыл җирлеге башлыгы В.И.Павлова